Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы
Васильевка авыл Советы

КАРАРЫ

03 июль 2023 ел № 78

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Васильевка авыл Советының 2013 елның 13 нче сентябрендәге номерлы 67 «Әлмәт муниципаль районы Васильевка авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалану мөмкинлеген тәэмин итү тәртибе хакында»гы карарга үзгәрешләр кертү хакында

«Дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалануны тәэмин итү хакында» 2009 елның 9 февралендәге 8-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы дәүләт органнары һәм Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалануны тәэмин итү хакында» 2015 елның 16 январендагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә

Васильевка авыл Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Васильевка авыл Советының 2013 елның 13 сентябрендәге 67 номерлы «Әлмәт муниципаль районы Васильевка авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалану мөмкинлеген тәэмин итү тәртибе хакында»гы ( Васильевка авыл Советының 2023 елның 20 февралендәге 68 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

карарга кушымтада:

9 бүлекнең 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә

«1. Җирле үзидарә органнары үз эшчәнлекләре турында мәгълүматны урнаштыру өчен «Интернет» челтәрен кулланалар, анда Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән таләпләргә туры китереп төзелгән һәм мәгълүмат кулланучы тарафыннан запрос җибәрелергә һәм соралган мәгълүмат алынырга мөмкин булган электрон почта адреслары күрсәтелгән рәсми сайтлар булдырыла. Җирле үзидарә органнары карары буенча ведомство карамагындагы оешмалар, башка федераль законнарда каралган очраклардан тыш, рәсми сайтлар булдыралар. Әгәр җирле үзидарә органы һәм аңа буйсынган оешмаларның рәсми сайтлар булдырырга мөмкинлекләре булмаса, аларның эшчәнлеге турында мәгълүмат муниципаль районның рәсми сайтында урнаштырыла.».

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Васильевка авылы, Үзәк урам, 26 йорт, Улаклы Чишмә авылы, Үзәк урам, 32а йорт территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендында игълан итәргә, «Татарстан Республикасы хокукый

мәгълүматының рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайтында “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыкканнан (халыкка җиткерелгәннән) соң үз көченә керә.

4.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны авыл Советы башлыгына йөкләргә.

Васильевка
авыл җирлеге башлыгы Ш.М.Касыймуллин

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН, МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ «ВАСИЛЬЕВСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ» АЛЬМЕТЬЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
ОГРН 1021601634264
ВАСИЛЬЕВСКИЙ СЕЛЬСКИЙ СОВЕТ
ИНН1644013931
КПП164401001